ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕОШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.54 а, с. Верхняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур., 54 а нче йорт, Югары Ушма авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

Карар
20 сентябрь 2017 ел

Постановление
№ 15

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел. 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14,22, 56 статьялары, " Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 п., «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитеты К А Р А Р БИРӘ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел пожар куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын булдыру :

Пожар гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру:

- Алкин торак пунктында, Хәсәнчә торак пунктында, Комазан Урманчылыгы торак пунктында.

2. Авыл җирлеге торак пунктларында су белән тәэмин итү:

Югары Ушма торак пунктында су алу башнясын әйләндереп алу

Комазан Урманчылыгы су башнясында ремонт эшләре алып бару

Су скважинасы әйләндереп алу: Югары Ушма, торак пунктларында

3.Җирлекнен торак пункт чикләренда жирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Югары Ушма торак пунктында Чапаев,Мөхәмәдиев урамыннарында,Ак Чишмә торак пунктында К.Маркс урамында юлны вакташ җәеп ремонтлау.

4. Ритуал хезмәтләрен оештыру һәм жирләү урыннарын саклау:

Иске Завод торак пунктында зират коймасын койма белән әйләндереп алу.

5. Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

Хәсәншә торак пунктында чишмәне төзекләндерү.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы М.Р.Хузязяновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге
башкарма
комитеты житәкчесе М.Р.Хузязянов